ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.05.2023_ Мөслим авылы №_244_

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга бер мәртәбә матди ярдәм күрсәтү комиссиясе төзү турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 20 апрелендәге 175 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Мөслим районы прокурорының 2023 елның 31 мартындагы 02-01-12-2023 номерлы коррупциоген факторны бетерү турындагы таләпләрен үтәү йөзеннән, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга бер мәртәбә матди ярдәм күрсәтү буенча комиссия төзү турында» 2021 елның 20 апрелендәге 175 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәреш кертергә:

1.1. «Авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү комиссиясе турында нигезләмә» 2 нче кушымтаның 4 пунктындагы 1 нче абзацы:

«4. Бер мәртәбә матди ярдәм күрсәтү турындагы карар һәм аның күләме, шулай ук бер мәртәбә матди ярдәм күрсәтүдән баш тарту турындагы карар Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән гаризаны теркәгән һәм беркетмәне рәсмиләштергән көннән алып 20 көннән дә артык булмаган вакытта кабул ителә.».

1.2. «Авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү тәртибе» 3 нче кушымтаның 5.4 пункты:

«5.4. Гражданнан килгән гариза Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан 10 көн эчендә карала һәм алга таба карау өчен авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга бер мәртәбә матди ярдәм күрсәтү комиссиясе турындагы нигезләмә нигезендә Комиссиягә җибәрелә.».

2. Мөслим муниципаль районындагы авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга бер мәртәбә матди ярдәм күрсәтү комиссиясе составына яңа редакциядә бәян итеп (1 нче кушымта) үзгәреш кертергә.

3. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының социаль-мәдәни үсеш буенча Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитеты җитәкчесе** **И.Ф. Салихҗанов**

Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
2023 елның «10» май
карарына 1 нче кушымта

Мөслим муниципаль районында авыр хәлдә калган гражданнарга бер мәртәбә матди ярдәм күрсәтү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Салихҗанов И.Ф. | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, *комиссия рәисе;* |
| Бәдретдинова М.Р. | Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары, *комиссия рәисе урынбасары;* |
| Сәетгәрәева З.Ф. | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының оештыру бүлеге баш белгече, *комиссия секретаре* (килешү буенча); |
| | *Комиссия әгъзалары:* |
| Әхмәтҗанов А.М. | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башлыгы урынбасары (килешү буенча); |
| Гарипов Р.Г. | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе (килешү буенча); |
| Бәдретдинов Н.А | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башлыгы ярдәмчесе (килешү буенча); |
| Бубекова Н.А | Мөслим муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча); |
| Гайсина Г.Р. | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы; |
| Сәйфиев И.Ф. | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше башлыгы; |
| Низамов И.Х. | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы ветераннар советы рәисе (килешү буенча); |
| Солтанов Р.З. | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Иҗтимагый Советы вәкиле (килешү буенча); |
| Хәбибуллина Л.Я. | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы; |
| Шәймәрдәнова Ф.Ф. | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Мәдәният бүлеге» МКУ башлыгы; |
| Җаббаров И. Р | Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы; |

| | |
|---|---|
| Фәтхуллина Г.Р. | Мөслим районындагы Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге башлыгы<br>(килешү буенча) |
| Сөләйманов Д.Т. | «Мөслим үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча); |
| Гыйльметҗанова Р.Р. | Мөслим муниципаль районында ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Маяк» халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге директоры (килешү буенча). |